СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №150-151 (7449-7450) | 19 декабрь, 1992 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ

### Татарстан Республикасы Конституциясен гамәлгә кертү тәртибе турында

# Татарстан Республикасы ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

**1 статья.** Татарстан Республикасының яңа Конституциясен, шушы Законның 5, 6, 7, 8, 9, 10 статьяларында каралган кагыйдәләреннән тыш, игълан ителгән көненнән гамәлгә кертергә. Шул вакыттан Татарстан Республикасының 1978 елда кабул ителеп, соңыннан үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән Конституциясен гамәлдән чыккан дип санарга.

**2 статья.** Татарстан Республикасының яңа Конституциясенә каршы килмәгән Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты Указлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, дәүләт органнарының башка актлары үз көчләрендә кала.

**3 статья.** Татарстан Республикасының яңа Конституциясен кабул иткәнче сайланган (билгеләнгән) Татарстан Республикасы Президенты, Югары Советы, Министрлар Кабинеты, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең башка органнары, шулай ук судьялар һәм прокурорлар чакырылыш (сайлану, билгеләнү) чорлары тәмамланганчы Татарстан Республикасының яңа Конституциясе тапшырган барлык вәкаләтләрне башкаралар дип санарга.

**4 статья.** Татарстан Республикасының Дәүләт (парламент) контроль комитеты, Конституциядә билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Югары Советының Парламент контроль комитетын сайлаганчыга кадәр эшли.

**5 статья.** Татарстан Республикасы Конституциясенең 71 статьясындагы: Татарстан Республикасы халык депутаты бүтән Советның депутаты була алмый, дигән кагыйдәсен Татарстан Республикасының яңа чакырылыш Югары Советы оешканнан соң гамәлгә кертергә.

**6 статья.** Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасы Югары Советының Закон чыгару җыены хакындагы статьяларындагы кагыйдәләр Закон чыгару җыены турында закон кабул иткәннән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә тиешле үзгәрешләр керткәннән соң гамәлгә керә.

**7 статья.** Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасы Югары Советы секретаре турындагы статьялары кагыйдәләрен Татарстан Республикасының яңа чакырылыш Югары Советы оешканнан соң гамәлгә кертергә.

**8 статья.** Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Конституция суды турындагы 140 статьясы кагыйдәсен Татарстан Республикасының Конституция судын сайлаганнан соң гамәлгә кертергә.

**9 статья.** Татарстан Республикасы Конституциясенең 72 статьясындагы: җирле администрация башлыгы урынбасарлары һәм администрациянең структура бүлекләре җитәкчеләре шушы җирле Советның депутаты була алмый, диелгән кагыйдәсен яңа чакырылыш җирле Советлар оешканнан соң гамәлгә кертергә.

**10 статья.** Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасы Тикшерү комитеты турындагы статьялары кагыйдәләрен Татарстан Республикасының Тикшерү комитеты турындагы законы кабул ителгәннән соң гамәлгә кертергә.

**11 статья.** Татарстан Республикасының яңа Конституциясе кабул ителүен исәпкә алып, Россия Федерациясе—Россия Югары Советына Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясе—Россия арасындагы мөнәсәбәтләрнең конституциячел килешүгә нигезләнгәнлеге турындагы кагыйдәләрне Россия Федерациясенең Төп Законында беркетү тәкъдиме белән мөрәҗәгать итәргә.

**12 статья** Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумына Татарстан Республикасында закон чыгару эшен оештыру һәм Татарстан Республикасы законнарын Татарстан Республикасының яңа Конституциясенә туры китерү тәртибен билгеләргә.

**13 статья.** Бу Закон басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты**
**М. ШӘЙМИЕВ.**

---

*Укучылар игътибарына*

**Газетабызның 148 нче санында А. Беляков исеменнән «Тырышлык кирәк әле» дигән баш астында әзерләнгән материалда фактлар, саннарда байтак төгәлсезлек җибәрелгән. Газета бу уңайдан үз укучыларыннан гафу үтенә һәм алар игътибарына әлеге тармакта эшләрнең объектив торышын чагылдырган материалны бу санда тәкъдим итә.**

# «Тырышлык кирәк әле»

Газетаның һәр санында диярлек район терлекчеләренең хезмәтен, уңышларын һәм җитешсезлекләрен чагылдырган сводкалар, информацияләр, рейд материаллары бирелеп килә. Бүген мин терлекчелек тармагындагы хәлләрне узган елгы җирлек белән чагыштырма планда яктыртырга телим. Бу җәһәттән гомуми торыш шуны күрсәтә: тармакта үткән ел белән чагыштырганда байтак уңай үзгәрешләр бар һәм аны киләчәктә дә шул ук дәрәҗәдә җаваплылык белән дәвам итәргә кирәк булачак. Иң мөһиме, район быел дәүләткә сөт һәм йон сату планнарын уңышлы үтәячәк. Районда 1 декабрьгә 12 хуҗалык аны уңышлы башкарып чыкты инде. «Ленинский путь», «Россия», Хафизов исемендәге, «Татарстан» колхозларында сөт сату планы күпкә арттырып—140,3—112,5 процентка гамәлгә ашырылды. Йон тапшыруда «Родина», «Комбайн», «Ленинский путь», Муса Җәлил исемендәге, «Таң» колхозлары план үтәлешен 177—127 процент итеп тәэмин иттеләр. Продукция сатуның уңышлы торышы, әлбәттә, җитештерүнең әйбәт баруына бәйле. Агымдагы елда Мичурин исемендәге, «Россия», Хафизов исемендәге, «Большевик», «Татарстан», 40 лет Победы», «Таң», «Үрнәк», «Кондырча», «Чирмешән», «Ленинский путь» колхозлары, «Рассвет» совхозы терлекчеләре 1 декабрьгә үк бер сыердан сөт җитештерүдә 3 меңле чикне байтакка уздылар, тулай продукция җитештерүдә дә алдагы ел белән чагыштырганда аерма ел ахырына кадәр бетереләчәк. Соңгысына, әлбәттә, мөгезле эре терлекләрнең узган ел белән чагыштырганда баш саны арту да үз йогынтысын ясамый калмады. Ул чагыштырма планда 2059 башка артты, бозаулар алу да бу чорда 157 башка күбрәк булды. Әлбәттә, сыерлар һәм таналарны каплатуда пошмаслыкка юл куелмаса, индивидуаль сектордан сөт җитештерү тиешенчә оештырылса, сөт җитештерү һәм сатуда тагы да югарырак нәтиҗәләрне тәэмин итү мөмкин булыр иде.

Шунысы куанычлы: 11 айда дәүләткә сатылган сөтнең 84 проценты 1 сорт белән тапшырылды, майлылык 3.66 процент тәшкил итте. Шуның нәтиҗәсендә генә дә зачет авырлыгында 3516 центнер продукция өстәп язылды. Киләчәктә сыйфатка мондый карашны саклаган хәлдә кәтүне яңарту, нәсел эшен эзлекле алып бару, малларны каплатуны вакытында үткәрү, үрчемнең сакланышына игътибарны көчәйтү, һәм, әлбәттә, малларны асрау, ашатуда зооветталәпләрне үтәү күз угындагы мөһим таләпләр булып калырга тиеш. Шуңа йөз тотканда киләчәктә дә тармакта эшләр тотрыклы, әйбәт барыр.

Кызганычка каршы, район ит тапшыру планын тулысынча үти алмаячак. 1 декабрьгә аны җитештерү дә узган елның шул чоры белән чагыштырганда 2273 центнерга азрак. Моның сәбәпләре күптөрле. Бер яктан терлекчеләр сарыкларның үлемен 592 гә киметсәләр, дуңгызларныкы 889 башка артты. Үрчем алуда да шундый ук хәл. Бозаулар алу 157 башка артса, дуңгыз балалары алу узган елгыдан 5152, бәрәннәр 644 башка азрак булды. Ә болар бит—нәкъ ит җитештерү чыганаклары.

Тәүлеклек үсеш алуда да шундый чуарлык. Район буенча мөгезле эре терлекләрнең тәүлеклек үсеше 543 грамм тәшкил итте, бу—үткән ел күрсәткеченнән 12 граммга артык. Хафизов исемендәге колхозда ул 973, Синдряков исемендәге колхозда 718, «Москва»да 772, «Яшь көч»тә 660 граммга җиткәндә, «Сөлчә»,«Мамык», «Тәрнәс» совхозларында, «Алга» колхозында 407—408 грамм дәрәҗәсендә генә. Дуңгызлардан артым алу район буенча 312 грамм тәшкил итте. Бу үткән елдагыдан 24 граммга кимрәк. Ә«Путь к коммунизму», «Знамя Октября» колхозларында, «Сөлчә» совхозында, Ульянов исемендәге, «Правда» колхозларында ул 99—204 грамм белән генә канәгатьләнә. Ә бит эшне дөрес оештырган хуҗалыкларда терлекчелек продукциясенең һәр төрен җитештерү һәм сату уңышлы үтәлеп килә. Мисалга «Россия» колхозын гына алыйк. Биредә дәүләткә сөт сату планы 123,1, итнеке 153,2 процент итеп гамәлгә ашырылган. Мичурин исемендәге колхозда шул тәртиптә планнар үтәлеше 101,3 һәм 102,7. «Рассвет» совхозында 109,8 һәм 101,1 процент тәшкил итә. Әйтәсе килгән фикер шул: эзлекле, нәтиҗәле хезмәт куелганда планнар реаль. без ит җитештерү һәм сатуда да хәлне бермә-бер яхшырта алабыз. Моның өчен ел башыннан терлекчелеккә игътибарлы караш, эшне зооветталәпләр нигезендә оештыру—бер сүз белән әйткәндә, уңышлы старт алу кирәк. Ә әйбәт башлангыч уңышка китергән шартларның иң мөһимнәреннән санала ул.

үзе сайлаган яки билгеләгән урындагы кешеләрнең хисабын даими тыңлый.

**90 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы Татарстан Республикасы законнарын һәм карарларын кабул итә.

**91 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы сайлаучылар саны нигездә тигез булган сайлау округларында сайланган 250 халык депутатыннан тора.

Татарстан Республикасы Югары Советы 125 Татарстан Республикасы халык депутатыннан торган Татарстан Республикасы Югары Советының даими эшләүче закон чыгару һәм контроль органын — Закон чыгару җыенын оештыра.

Татарстан Республикасы Югары Советы Закон чыгару җыенының вәкаләте, аның оешу һәм эшчәнлек тәртибе Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Югары Советының Закон чыгару җыены турындагы законы белән билгеләнә.

**92 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы беренче утырышка Югары Советның билгеләнгән санлы составының кимендә өчтән ике өлеше сайланганнан соң ике айдан да соңга калмыйча чакырыла.

Татарстан Республикасы Югары Советының сайлаудан соң беренче утырышын Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлау буенча Үзәк сайлау комиссиясе рәисе ача һәм алып бара, ә Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе сайлангач, утырышны Рәис алып бара.

**93 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советының эш тәртибе шушы Конституция һәм Югары Совет регламенты белән билгеләнә.

Татарстан Республикасы Югары Советының вәкаләтләр чоры гадәттән тыш хәл вакытында бетсә, Татарстан Республикасы Югары Советы гадәттән тыш хәл кертелү турындагы мәсьәләне хәл итү белән бергә, үз вәкаләтләре чорын озайту турында да карар кабул итә.

**94 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советында закон чыгару инициативасы хокукына Татарстан Республикасы халык депутатлары, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы, даими комиссияләре һәм Парламент контроле комитеты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Конституция суды, Югары суды һәм Югары арбитраж суды, Татарстан Республикасы прокуроры, шулай ук Хезмәт мөнәсәбәтләре һәм хезмәт ияләрен социаль яклау мәсьәләләре буенча профессиональ союзларның республика советы ия.

**95 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы каравына кертелгән закон проектлары аның утырышларында тикшерелә.

Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Югары Советының билгеләнгән санлы составының яртысыннан күбрәге яклап тавыш биргәндә, кабул ителгән дип санала.

Закон проектлары һәм дәүләт тормышының башка аеруча мөһим мәсьәләләре Татарстан Республикасы Югары Советының яки аның Президиумының карары белән халык тикшерүенә чыгарылырга мөмкин.

**96 статья.** Татарстан Республикасы законнары татар һәм рус телләрендә кабул ителә һәм бастырып чыгарыла.

**97 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы Татарстан Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә үз каравына тапшырылган мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итә һәм Татарстан Республикасы Югары Советы эшен оештыруны тәэмин итә; Президиум Югары Советка хисап бирә.

Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумына Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе, Рәисенең урынбасарлары һәм секретаре, Татарстан Республикасы Югары Советының даими комиссияләре, Парламент контроле комитеты рәисләре һәм Татарстан Республикасы Югары Советы сайлаган башка депутатлар керә.

Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумын Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе җитәкли.

**98 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы:

1) Татарстан Республикасы Югары Советы сессияләрен чакыра һәм аның утырышларын әзерләүне оештыра;

2) Татарстан Республикасы Югары Советының даими һәм башка комиссияләре, Парламент контроле комитеты эшчәнлеген яраштыра;

3) Татарстан Республикасы халык депутатларына үз вәкаләтләрен үтәргә булыша һәм аларны кирәкле мәгълүмат белән тәэмин итә;

4) халыкның тавыш бирүен (референдумнарны), шулай ук Татарстан Республикасы закон проектларын һәм дәүләт тормышының аеруча мөһим башка мәсьәләләрен халык тикшерүенә әзерләүне һәм аны үткәрүне оештыра;

5) Татарстан Республикасы Югары Советы. Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы кабул иткән Татарстан Республикасы законнарын һәм башка актларны бастырып чыгара;

6) халык депутатларының җирле Советлары эшчәнлегенә юнәлеш бирә;

7) халык депутатларының район һәм шәһәр (республика буйсынуындагы шәһәр) Советларының законга туры килмәгән карарларын гамәлдән чыгара;

8) Татарстан Республикасының административ-территория төзелеше мәсьәләләре буенча карарлар кабул итә;

9) Татарстан Республикасы законнарында каралган башка мәсьәләләрне хәл итә.

**99 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы карарлар кабул итә.

**100 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советының вәкаләт срогы беткәннән соң, Татарстан Республикасы Югары Советы Югары Советның яңа Президиумын оештырганчы, Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы үз вәкаләтләрен саклый.

**101 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе — Татарстан Республикасы Югары Советының иң югары урындагы кешесе, республиканың башка органнары, шулай ук башка дәүләтләр парламентлары белән мөнәсәбәтләрдә Югары Совет исеменнән эш итә һәм Югары Советның, аның Президиумының эшен оештыра:

1) Татарстан Республикасы Югары Советы карарга тиешле мәсьәләләрне әзерләүгә гомуми җитәкчелек итә, Татарстан Республикасы Югары Советы һәм Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы кабул иткән карарларга кул куя;

2) Татарстан Республикасы Югары Советына Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе урынбасарлары һәм Секретаре вазифаларына сайлау өчен кандидатлар, Татарстан Республикасы Югары судының һәм Югары арбитраж судының шәхси составын, Конституция суды шәхси составының яртысын тәкъдим итә.

Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе урынбасарлары, Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе кушуы буенча, аның аерым вазифаларын үтиләр һәм, Рәис булмаган яки ул үз вазифасын үти алмаган очракта, аны алыштыралар.

Татарстан Республикасы Югары Советы Секретаре Югары Совет секретариаты аппараты белән җитәкчелек итә.

**102 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы закон проектларын эшләү, Татарстан Республикасы Югары Советы тикшерәчәк мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен, шулай ук Татарстан Республикасы законнарын һәм Татарстан Республикасы Югары Советы кабул иткән башка карарларны гамәлгә ашырырга булышлык итү, дәүләт органнары һәм оешмалары эшчәнлегенә контрольлек итү өчен халык депутатларыннан даими комиссияләр төзи.

Комиссияләрнең закон бозуларны бетерүгә юнәлтелгән карарларын үтәү мәҗбүри.

Татарстан Республикасы Югары Советы, даими комиссияләренең вәкаләте, оешу һәм эш тәртибе закон белән билгеләнә.

Татарстан Республикасы Югары Советы, кирәк тапса, теләсә нинди мәсьәлә буенча тикшерү, ревизия комиссияләре һәм башка комиссияләр төзи.

**103 статья.** Татарстан Республикасы законнары, кагыйдә буларак, аларның проектлары Татарстан Республикасы Югары Советының тиешле даими комиссияләрендә алдан тикшерелгәннән соң кабул ителә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Конституция суды, Югары суды һәм Югары арбитраж суды составларына урындагы кешеләр, шулай ук Татарстан Республикасы прокуроры һәм Тикшерү комитеты рәисе кандидатларны Татарстан Республикасы Югары Советының тиешле даими комиссияләрендә алдан караганнан соң билгеләнә һәм сайлана.

**104 статья.** Татарстан Республикасы халык депутаты Татарстан Республикасы Югары Советы утырышларында Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Премьер-министрына, министрларына, Татарстан Республикасы Югары Советы төзегән яки сайлаган башка органнарның (судлардан кала) җитәкчеләренә таләп белән мөрәҗәгать итәргә хаклы. Таләп бирелгән орган яки урындагы кеше өч көннән дә соңга калмыйча җавап бирергә тиеш.

Татарстан Республикасы халык депутаты Татарстан Республикасы Югары Советы ризалыгыннан башка җинаять җаваплылыгына тартыла алмый, кулга алына алмый яки суд билгеләгән административ җәзага тартыла алмый.

**105 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы үзенә буйсынган барлык дәүләт органнарының эшен контрольдә тота.

## 11 бүлек. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ

**106 статья.** Татарстан Республикасында дәүләт башлыгы — Президент.

**107 статья.** Татарстан Республикасы Президенты — Татарстан Республикасында шәхес хокуклары һәм ирегенең, республика суверенитетының, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара килешүләрен үтәүнең гаранты.

**108 статья.** Татарстан Республикасы Президенты итеп республиканың утыз биштән яшьрәк; алтмыш биш яшьтән өлкәнрәк булмаган, сайлау хокукына ия булган, Татарстан Республикасы территориясендә ким дигәндә ун ел даими яшәүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләрен белүче гражданы сайлана ала. Бер үк кеше рәттән ике сроктан да артык Татарстан Республикасы Президенты була алмый.

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы гражданнары тарафыннан гомуми, тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән биш елга сайлана. Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар саны чикләнми. Сайлаучыларның яртысыннан күбрәге сайлауда катнашса, Татарстан Республикасы Президентын сайлау үткәрелгән дип санала. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның яртысыннан күбрәгенең тавышын алган кандидат сайланган дип исәпләнә.

Президент белән бер үк вакытта Татарстан Республикасы вице-президенты да сайлана.

Татарстан Республикасы Президентын һәм вице-президентын сайлау тәртибе Татарстан Республикасы Президентын сайлау турында Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә.

**109 статья.** Татарстан Республикасы Президенты һәм вице-президенты башка урында эшли алмый, шулай ук Татарстан Республикасы һәм халык депутатлары җирле Советларының халык депутаты була алмый.

**110 статья.** Татарстан Республикасы Президенты үз вазифасын үтәүгә керешкәндә сайлау йомгаклары игълан ителгәннән соң бер ай эчендә Татарстан Республикасы халкына һәм Конституциясенә тугрылыгын белдереп ант итә. Антның текстын һәм аны кабул итү тәртибен Татарстан Республикасы Югары Советы раслый.

**111 статья.** Татарстан Республикасы Президенты:

1) Татарстан Республикасы гражданнарының хокукларын һәм ирекен, Татарстан Республикасының дәүләт суверенитетын, республиканың иминлеген һәм территория бөтенлеген, аның территориясендә законлылыкны һәм хокук тәртибен тәэмин итә;

2) Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары системасына җитәкчелек итә һәм аларның Татарстан Республикасы Югары Советы белән бергәләшеп эшләвен тәэмин итә;

3) җирле администрацияләр эшчәнлегенә юнәлеш бирә, халык депутатларының тиешле Советлары ризалыгы белән район һәм республика буйсынуындагы шәһәр администрациясе башлыкларын билгели һәм эштән азат итә;

4) Татарстан Республикасы Югары Советына ел саен Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты проектын, республиканың эчке һәм тышкы хәле турында докладлар тәкъдим итә, Югары Советка республика тормышының мөһим мәсьәләләре турында мәгълүмат бирә; Татарстан Республикасы Югары Советы һәм аның Президиумы эшендә катнашырга хаклы;

5) Татарстан Республикасы Югары Советы раславына Татарстан Республикасы Премьер-министры урынына кандидат тәкъдим итә. Татарстан Республикасы Югары Советы белән килешеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын оештыра, аның составына үзгәрешләр кертә, Татарстан Республикасы Премьер-министрын һәм Министрлар Кабинеты әгъзаларын эштән азат итә. Татарстан Республикасы Югары Советына Татарстан Республикасы министрлыкларын һәм дәүләт комитетларын оештыру һәм бетерү турында тәкъдим кертә;

6) Татарстан Республикасы Югары Советы раславына Татарстан Республикасы Милли банкы рәисе урынына кандидат тәкъдим итә;

7) Татарстан Республикасы Югары Советына Татарстан Республикасы Конституция судының шәхси составының яртысын тәкъдим итә;

8) Татарстан Республикасы Югары Советына Татарстан Республикасы прокуроры, Татарстан Республикасы Тикшерү комитеты рәисе урынына кандидатлар тәкъдим итә, шулай ук Татарстан Республикасы Югары Советына аларны эштән азат итү турында тәкъдим кертә;

9) халыкара мөнәсәбәтләрдә Татарстан Республикасы исеменнән эш

ламәтлеген, шәхси иреген һәм иминлеген яклый.

**26 статья.** Татарстан Республикасы гражданнарына шәхес кагылгысызлыгы гарантияләнә. Беркем дә законсыз кулга алына һәм ирегеннән мәхрүм ителә алмый. Кулга яки сак астына алынган очракта граждан бу хакта кичекмәстән судка шикаять бирергә хаклы. Хокук бозган өчен җавапка тартылган граждан закон һәм хокукый процедура чикләрендә гаебе исбатланганга кадәр гаепсез дип санала.

Татарстан Республикасы гражданнарына яклану хокукы гарантияләнә.

**27 статья.** Татарстан Республикасы гражданнарына торак кагылгысызлыгы гарантияләнә. Законлы сәбәп булмаганда торакка керергә, анда яшәүчеләр ризалыгыннан башка тентү үткәрергә беркемнең дә хакы юк.

**28 статья.** Татарстан Республикасы гражданнарына хат алышу, телефоннан сөйләшү, телеграф һәм хәбәрләшүнең башка төрләрендә сер саклау тәэмин ителә.

**29 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары, инануларына карап, теләсә кайсы динне тотарга ирекле яисә берсен дә тотмаска, дини яки атеистик эшчәнлек белән шөгыльләнергә хокуклы. Дини йолаларны үтәүдә һәркем ирекле.

Дини инануларга бәйле рәвештә дошманлык, нәфрәт һәм милли ызгыш уяту тыела.

Татарстан Республикасында диннәр һәм дини берләшмәләр дәүләттән аерылган.

**30 статья.** Гаилә, ана, ата һәм балалар дәүләт яклавында. Никах хатын-кыз белән ир-атның ирекле килешүенә нигезләнә: гаилә мөнәсәбәтләрендә хатын белән ир тигез хокуклы. Гражданнарның гаилә тормышы закон белән саклана.

Дәүләт гаилә турында кайгырта, ана белән баланың сәламәтлеген саклауга һәм балаларны тәрбияләүгә аерым игътибар бирә.

Татарстан Республикасы гражданнары үз балаларын тәрбияләү өчен җаваплы. Балигъ булган балалар ата-аналарын кайгыртырга һәм аларга ярдәм күрсәтергә бурычлы.

**31 статья.** Һәр граждан Татарстан Республикасы территориясендә ирекле күчеп йөрүгә, яшәү һәм тору урынын сайлауга хаклы. Бу хокукны закон гына чикли ала.

**32 статья.** Һәр кеше Татарстан Республикасы территориясеннән ирекле рәвештә китәргә һәм республикага әйләнеп кайтырга хокуклы.

**33 статья.** Шәхесне ихтирам итү, гражданнарның хокукларын һәм иреген саклау — барлык дәүләт органнарының, җәмәгать берләшмәләре һәм урындагы кешеләрнең бурычы.

Татарстан Республикасы гражданнары намусына һәм абруена, тормышына һәм сәламәтлегенә, шәхси ирегенә һәм мөлкәтенә кул сузудан суд аша якланырга хокуклы.

**34 статья.** Һәр граждан урындагы кешеләрнең, дәүләт органнары һәм җәмәгать оешмаларының гамәленә карата судка шикаять бирергә, шулай ук әхлакый һәм матди зыянны түләтергә хокуклы.

**35 статья.** Татарстан Республикасында һәркемгә сүз, матбугат, фикер һәм инану иреге, аларны тоткарлыксыз белдерү һәм тарату иреге гарантияләнә.

**36 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары закон билгеләгән тәртиптә тыныч һәм коралсыз митинг, урамда оешып йөрү, демонстрация һәм пикетлар оештыруга хокуклы.

**37 статья.** Халык мәнфәгатьләренә туры килеп һәм иҗтимагый активлыкны күтәрү максатында Татарстан Республикасы гражданнары сәяси партияләргә, профессиональ союзлар, массакүләм хәрәкәтләргә һәм башка җәмәгать берләшмәләренә берләшергә, гамәлдәге законнар чикләрендә гражданлык инициативасы тәртибендәге чараларда катнашырга хокуклы. Дәүләт аларга устав бурычларын үтәүдә булыша.

Хакимиятнең вәкиллекле органнарында каршы фикерле азчылыкны тәшкил итүчеләрнең хокуклары, иреге һәм кешелек абруе закон белән гарантияләнә.

Эшчәнлекләре Конституциягә каршы килгәндә, сәяси партияләр, профессиональ союзлар, массакүләм хәрәкәтләр һәм башка җәмәгать берләшмәләре суд карары белән таратыла ала.

**38 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары сәяси тормышта, дәүләт һәм җәмәгать эшләрен идарә итүдә, гомумреспублика һәм җирле әһәмияттәге законнарның һәм карарларның проектын тикшерүдә, референдумнарда катнашырга хокуклы.

**39 статья.** Закон нигезендә һәр гражданга дәүләт хезмәтенә керү өчен тигез хокук гарантияләнә.

**40 статья.** Татарстан Республикасының һәр гражданы дәүләтнең эчке һәм халыкара тормышының барлык өлкәләре, шул исәптән шәхеснең хокукый статусы мәсьәләләре турында дөрес мәгълүматны тоткарлыксыз алырга һәм таратырга хокуклы.

Дәүләт органнары, җәмәгать берләшмәләре һәм урындагы кешеләр гражданга аның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы карарлар һәм башка материаллар белән танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

**41 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары милеккә һәм аны мирас итүгә хокуклы.

**42 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары хезмәткә, ягъни һөнәрен һәм эш урынын саклау, хезмәткә сәләтен файдалану ирегенә хокуклы. Хезмәт килешүе иреге гарантияләнә.

Һәркем хәвефсезлек һәм гигиена таләпләренә туры килә торган хезмәт шартларына, хезмәтенә закон билгеләгән иң аз күләмнән дә ким булмаган түләүгә хокуклы.

Нинди милеккә ия булуларына карамастан, барлык предприятие, учреждение һәм оешмаларда дәүләт эшкә алуның, эштән бушатуның һәм хезмәтне саклауның гадел шартларын, аларда эшләүчеләрнең хезмәт хокукларын һәм үз мәнфәгатьләрен яклау ирeген гарантияли.

Дәүләт балигъ булмаган, физик һәм психик кимчелекле кешеләрнең хезмәткә хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра, гарипләрне, мохтаҗ һәм даими эше булмаган гражданнарны социаль яклауны гарантияли, кирәк очракта аларны өйрәтүне һәм квалификацияләрен үзгәртүне оештыра.

Мәҗбүри хезмәткә суд карары белән, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара килешүләрендә каралган очракларда гына юл куела.

**43 статья.** Татарстан Республикасы гражданнарына ялга һәм эштән буш вакытка хокук гарантияләнә. Бу хокук 40 сәгатьтән артык булмаган эш атнасы билгеләү, хезмәт ияләренә ел саен түләүле ял, атна саен ял көннәре бирү, буш вакытны файдалы үткәрү өчен шартлар тудыру белән тәэмин ителә.

**44 статья.** Татарстан Республикасының һәр гражданы сәламәтлеген саклауга, шул исәптән сәламәтлек саклауның дәүләт һәм башка учреждениеләре закон тәртибендә күрсәтә торган медицина ярдәменә хокуклы.

Дәүләт гражданнарның сәламәтлеген ныгытуга, физик культура һәм спортны үстерүгә ярдәм итүче эшчәнлекне хуплый.

**45 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары чиста табигать мохитенә хокуклы.

**46 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары картлыкта, авырганда, хезмәткә сәләтен тулысынча яки өлешчә югалтканда, бала табып, аны закон билгеләгән яшькә җиткергәндә, туендыручысын югалтканда, шулай ук законда күздә тотылган башка нигезләрдә һәм күләмдә матди тәэмин ителүгә хокуклы.

**47 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары торакка хокуклы. Бу хокук дәүләт һәм җәмәгать торак фондын үстерү, кооператив һәм шәхси торак төзелешенә булышу белән тәэмин ителә. Законда билгеләнгән очраклардан тыш, беркем дә торагыннан мәхрүм ителә алмый.

**48 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары дәүләт уку йортларында түләүсез гомуми урта һәм махсус урта белем алырга, шулай ук мәктәптә туган телендә укырга хокуклы.

Татарстан Республикасы гражданнары дәүләт уку йортларында конкурс нигезендә түләүсез югары белем алырга хокуклы.

**49 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары мәдәният казанышларыннан файдаланырга хокуклы. Һәр кешегә фәндә, техникада һәм сәнгатьтә иҗат ирeге гарантияләнә.

Автор, уйлап табучы һәм рационализатор хокуклары дәүләт тарафыннан саклана.

**50 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары икътисадый һәм социаль мәнфәгатьләрен яклау өчен, күмәк хезмәт бәхәсен хәл итүнең соңгы чарасы буларак, законда каралган эш ташлауга хокуклы.

Беркем дә эш ташлауда катнашырга мәҗбүр ителә алмый.

Кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырырлык эш ташлауга юл куелмый.

**51 статья.** Гражданнарның Конституция игълан иткән хокукларны һәм ирекне файдалануы дәүләт һәм җәмәгать иминлегенә, җәмәгать тәртибенә, халыкның сәламәтлегенә һәм әхлагына, башка кешеләрнең хокукларына һәм ирегенә зыян китермәскә тиеш.

**52 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә бурычлы.

**53 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары башка кешеләрнең хокукларын һәм законнары мәнфәгатьләрен ихтирам итәргә бурычлы.

Башка гражданнарның намусын һәм милли горурлыгын ихтирам итү — Татарстан Республикасының һәр гражданы бурычы.

**54 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары, закон тәртибендә салымнар түләп, дәүләт чыгымнарында катнашырга бурычлы.

**55 статья.** Табигатькә сакчыл мөнәсәбәт — Татарстан Республикасының һәр гражданы бурычы.

**56 статья.** Мәдәни хәзинәләрне, тарихи истәлекләрне саклау — Татарстан Республикасы гражданнарының бурычы.

Мәдәни истәлекләрне бозган һәм юкка чыгарган өчен закон нигезендә җәза бирелә.

**57 статья.** Башка илләрнең халыклары белән дуслык һәм хезмәттәшлекне үстерүгә булышу, гомумтанылган халыкара хокук нормалары нигезендә бөтен дөньяда тынычлыкны саклау һәм ныгыту — Татарстан Республикасы гражданнарының бурычы.

**58 статья.** Татарстан Республикасы гражданнары закон нигезендә хәрби хезмәт үтәргә бурычлы. Хәрби хезмәт Татарстан Республикасы территориясендә яки Татарстан Республикасының килешү йөкләмәләре нигезендә аннан читтә үтелә.

Хәрби хезмәтне альтернатив вазифалар белән алыштыру, шулай ук хәрби хезмәттән азат итү закон белән билгеләнә.

## III. Татарстан Республикасының дәүләт төзелеше

### 5 бүлек. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ — СУВЕРЕН ДӘҮЛӘТ

**59 статья.** Татарстан Республикасы үзенең дәүләти-хокукый статусын, сәяси, икътисадый, социаль-мәдәни төзелеше мәсьәләләрен мөстәкыйль билгели һәм хәл итә. Татарстан Республикасы законнары, әгәр алар Татарстан Республикасының халыкара йөкләмәләренә каршы килмәсә, аның бөтен территориясендә өстенлеккә ия.

**60 статья.** Татарстан Республикасы территориясе — кагылгысыз. Татарстан Республикасы белән башка дәүләтләр арасындагы чикләр үзара килешү нигезендә билгеләнә һәм үзгәртелә.

**61 статья.** Татарстан Республикасы Россия Федерациясе — Россия белән вәкаләтләрен һәм ике якка да караган эшләрне тапшырышу турындагы Килешү нигезендә ассоциацияләшкән суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты.

**62 статья.** Татарстан Республикасы башка дәүләтләр белән мөнәсәбәткә керә, халыкара килешүләр төзи, дипломатия, консуллык, сәүдә һәм башка вәкиллекләр алмаша, халыкара хокук принципларына нигезләнеп, халыкара оешмалар эшчәнлегендә катнаша.

Гомумтанылган халыкара хокук принциплары һәм нормалары Татарстан Республикасы законнарыннан өстенрәк санала.

### 6 бүлек. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АДМИНИСТРАТИВ-ТЕРРИТОРИЯ БҮЛЕНЕШЕ

**63 статья.** Татарстан Республикасы территориясе — районнарга һәм республика буйсынуындагы шәһәрләргә, районнар — шәһәрләргә, поселокларга һәм авыл Советларына, зур шәһәрләр районнарга бүленә.

## IV. Татарстан Республикасында дәүләт хакимиятен оештыру

### 7 бүлек. ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ СОВЕТЛАРЫНЫҢ ОЕШУ ҺӘМ ЭШ НИГЕЗЛӘРЕ

**64 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы, җирле Советлар — шәһәр, район, шәһәрдәге район, поселок һәм авыл Советлары — Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органнарының бердәм системасын тәшкил итә.

Халык депутатлары Советлары үз вәкаләтендәге барлык мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итә.

Поселокларда, авыл Советларында, шул Советның карары яки җирле референдум нигезендә, Совет сайланмаска яисә бетерелергә мөмкин. Мондый очракта поселок, авыл Советының вәкаләтләрен җирле үзидарәнең башка органнары гамәлгә ашыра.

**65 статья.** Республика һәм аның аерым урыннары өчен әһәмиятле төп мәсьәләләр Татарстан Республикасы Югары Советы һәм халык депутатлары җирле Советлары сессияләрендә хәл ителә. Алар шулай ук республика күләмендәге һәм җирле референдумга куелырга мөмкин.

**66 статья.** Татарстан Республикасы Югары Советы, халык депутатларының район, шәһәр, шәһәрдәге район Советлары — Совет президиумын һәм рәисен, ә район буйсынуындагы шәһәр, поселок һәм авыл Советлары Совет рәисен сайлыйлар.

Халык депутатлары Советы комитетлар, даими һәм вакытлы комиссияләр, аңа буйсынган башка органнар оештыра, шулай ук аларның җитәкчеләрен сайлый яки раслый.

һәм оешмаларның эшчәнлеген яраштыра һәм аңа контрольлек итә; законда каралган башка эшләрне гамәлгә ашыра.

**133 статья.** Җирле администрация халык депутатларының шул җирле Советына һәм югарыгы башкару һәм боеру органнарына хисап бирә.

**134 статья.** Җирле администрациянең эшчәнлегенә администрация башлыгы җитәкчелек итә. Районның, республика буйсынуындагы шәһәрнең администрация башлыгы, халык депутатларының шул Советы ризалыгы белән, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

Шәһәр районы, район буйсынуындагы шәһәр, поселок, авыл Советы администрация башлыгы, халык депутатларының шул Советы ризалыгы белән, югарыгы администрация башлыгы тарафыннан билгеләнә.

Җирле администрация башлыгы үз вәкаләтләре чикләрендә карар һәм боерыклар чыгара.

Җирле администрация башлыгының законнарга туры килми торган актларын халык депутатлары Советлары, тиешле административ -территория берәмлегенең югарыгы башкару-боеру органы яки суд гамәлдән чыгара.

# V. Суд хакимияте, законлылыкны һәм хокук тәртибен саклау

## 14 бүлек. СУДЛАР

**135 статья.** Татарстан Республикасында суд хакимиятенә бары судлар гына ия.

Суд хакимияте Татарстан Республикасының конституциячел төзелешен, гражданнарның хокукларын һәм ирекен яклау, закон чыгару һәм башкару хакимияте актларының Татарстан Республикасы Конституциясенә, законнарны үтәгәндә һәм кулланганда аларның законлылыкка һәм социаль гаделлеккә туры килүләрен тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.

Судлар закон чыгару һәм башкару органнарына, шулай ук җәмәгать берләшмәләренә бәйле түгел. Татарстан Республикасы Конституциясендә каралган суд органнарыннан башка, беркемнең дә суд вазифаларын һәм вәкаләтләрен үзенә алырга хокукы юк.

**136 статья.** Татарстан Республикасында суд хакимиятен Конституция суды, гомуми судлар һәм Югары арбитраж суды гамәлгә ашыра.

Суд органнарының закон көченә кергән актлары барлык дәүләт һәм җәмәгать органнары, урыннардагы кешеләр һәм гражданнар өчен мәҗбүри һәм Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәлергә тиеш.

Суд органнарының закон көченә кергән актларын үтәмәгән, суд эшчәнлегенә тыкшынган, судка ихтирамсызлык күрсәткән өчен законда җаваплылыкка тарту каралган.

**137 статья.** Барлык судларда эшләр ачык утырышларда карала. Эшләрне ябык тыңлау, бары тик суд эшләрен алып баруның барлык кагыйдәләрен саклап, законда билгеләнгән очракларда гына рөхсәт ителә.

**138 статья.** Судья депутат була алмый, башка дәүләт, хуҗалык, җәмәгать органнарында һәм оешмаларында хезмәт хакы алып эшли алмый, эшмәкәрлек белән шөгыльләнә алмый. Судьяга фәнни һәм укыту эшчәнлеге рөхсәт ителә.

Судьялар алыштырылмый, аларның кагылгысызлыгы закон белән гарантияләнә. Законда каралган яшькә җиткәч, алар отставкага чыгарыла.

**139 статья.** Татарстан Республикасы Конституция суды Конституция судының рәисеннән, рәис урынбасарыннан һәм әгъзаларыннан тора; алар Татарстан Республикасының 30 дан яшьрәк, 65 яшьтән өлкәнрәк булмаган, сайлау хокукына, Конституция суды судьясы вазифаларын башкару өчен кирәкле югары квалификациягә һәм әхлак сыйфатларына, югары юридик белемгә, шулай ук гыйльми дәрәҗәгә ия булган яисә юридик белгечлек буенча кимендә ун ел эшләгән гражданнарыннан сайлана.

Конституция суды судьяларына кандидатларны Татарстан Югары Советына Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе тигез санда күрсәтәләр.

Конституция суды рәисе һәм рәис урынбасары Конституция суды судьялары тәкъдиме белән, Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан раслана.

Конституция суды судьялары бәйсез һәм бары Татарстан Республикасы Конституциясенә буйсыналар.

**140 статья.** Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасының конституция төзелешен, кешенең төп хокукларын һәм ирекен яклау, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә Татарстан Республикасы Конституциясенең өстенлеген һәм турыдан-туры гамәлдә булуын тәэмин итү максатында:

1) Татарстан Республикасы законнарының һәм Татарстан Республикасы Югары Советы норматив карарларының;

2) Татарстан Республикасы Президенты һәм Министрлар Кабинеты норматив актларының;

3) Татарстан Республикасының халыкара килешүләренең Конституциягә туры килү-килмәве турындагы эшләрне тикшерә.

Конституция суды Татарстан Республикасының югары дәүләт органнары арасындагы, шулай ук районнарның һәм республика буйсынуындагы шәһәрләрнең хакимият органнары арасындагы вәкаләтләр турындагы бәхәсләрне карый.

Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасы Югары Советы, аның даими комиссияләре һәм Парламент контроле комитеты таләпләре нигезендә, шулай ук үз инициативасы белән, Татарстан Республикасы Президенты эшләренең һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турында бәяләмә бирә.

Конституция суды тарафыннан Конституциягә туры килми дип табылган актлар яки аларның аерым өлешләре, законда каралган очракларда, суд карары игълан ителгән көннән көчен югалта. Конституция суды карарлары—катгый; аларга дәгъва яки шикаять белдерелми.

**141 статья.** Конституция судының вәкаләтләре, оешу һәм эш тәртибе, судьяларның статусы Татарстан Республикасы Конституция суды турында Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә.

**142 статья.** Татарстан Республикасы Югары суды, район (шәһәр) судлары Татарстан Республикасының гомуми вәкаләтле судлары була. Татарстан Республикасы законнары тарафыннан аерым төр эшләрне (балигъ булмаганнар, гаилә һәм башкалар турындагы эшләрне) карау өчен махсус суд составлары оештыру да күздә тотылуы мөмкин.

Татарстан Республикасында аерым вәкаләтле судлар оештырыла алмый.

Гомуми вәкаләтле судларны оештыру һәм аларның эш тәртибе Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

**143 статья.** Татарстан Республикасында барлык судлар судьяларны һәм халык утырышчыларын сайлау нигезендә оештырыла.

Татарстан Республикасының район (шәһәр) судлары, Югары суды судьяларын Татарстан Республикасы Югары Советы сайлый.

Район (шәһәр) судларының халык утырышчылары гражданнарның тору яки эш урыннарындагы җыелышларда—ачык тавыш биреп, ә Татарстан Республикасы Югары суды халык утырышчылары Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан 5 елга сайлана. Халык утырышчылары хезмәтенә дәүләт исәбеннән түләнә.

Судьялар һәм халык утырышчылары законда билгеләнгән тәртиптә һәм нигездә чакыртып алынырга мөмкин.

**144 статья.** Татарстан Республикасы Югары суды—Татарстан Республикасында суд эшләрен алып баручы һәм Татарстан Республикасы законнары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гомуми вәкаләтле судлар эшчәнлегенә күзәтчелек итүче иң югары суд органы. Татарстан Республикасы Югары суды рәистән, рәис урынбасарларыннан, судьялардан һәм халык утырышчыларыннан тора.

**145 статья.** Барлык судларда гражданлык һәм җинаять эшләре, законда билгеләнгән очраклардан тыш, коллегиаль рәвештә карала.

Суд эшләрен гамәлгә ашырганда халык утырышчылары судьяларга бирелгән барлык хокуклардан файдалана.

Законда үлем җәзасы күздә тотылган җинаятьләр турындагы эшләр буенча хөкем ителүче кешенең гаеплелеге хакындагы мәсьәлә халык утырышчыларының киңәйтелгән коллегиясендә (присяжныйлар судында) хәл ителергә мөмкин.

**146 статья.** Судьялар һәм халык утырышчылары бәйсез һәм бары законга буйсына.

Судьяларга һәм халык утырышчыларына хокукларын һәм вазифаларын каршылыксыз һәм нәтиҗәле башкару өчен шартлар тәэмин ителә. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җәмәгать берләшмәләре, урындагы кешеләр һәм гражданнарның судьялар һәм халык утырышчыларының суд эшләрен башкару эшчәнлегенә тыкшынуы тыела, моның өчен законда билгеләнгән тәртиптә җавапка тарту карала.

Судьяларның һәм халык утырышчыларының кагылгысызлыгы, шулай ук аларның бәйсезлегенең башка гарантияләре закон белән билгеләнә.

**147 статья.** Гомуми вәкаләтле судларда эшләр гражданнарның чыгышына, хезмәт урынына, социаль һәм милек хәленә, нинди расадан һәм милләттән булуына, җенесенә, белеменә, теленә, дингә мөнәсәбәтенә, шөгыленең төренә һәм үзенчәлегенә, яшәү урынына һәм башкаларга бәйсез рәвештә аларның закон каршында тигезлекләренә карап хәл ителә.

**148 статья.** Гаеп кылуда шикле кеше, гаепләнүче һәм хөкем ителүче яклану хокукына ия.

Сорау алучы, тикшерүче, прокурор һәм суд гаеп кылуда шикле кешегә, гаепләнүчегә һәм хөкем ителүчегә законда билгеләнгән чаралар һәм ысуллар белән үзен яклау мөмкинлеген, шулай ук аларның шәхес һәм милек хокукларын саклауны тәэмин итәргә бурычлы.

**149 статья.** Татарстан Республикасында суд эшләре татар һәм рус телләрендә яки шул урында яшәүче күпчелек халык телендә алып барыла. Суд эшендә катнашкан һәм суд эше бара торган телне белмәгән кешеләргә тәрҗемәче ярдәмендә эшнең барлык материаллары белән танышу, судта катнашу һәм анда туган телендә чыгыш ясау хокукы тәэмин ителә.

**150 статья.** Татарстан Республикасы прокуроры һәм аңа буйсынган прокурорлар судларда эшләрне карауда Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән нигездә һәм тәртиптә катнаша.

**151 статья.** Судта гражданлык һәм җинаять эшләре каралганда, җәмәгать берләшмәләре һәм хезмәт коллективлары вәкилләренең катнашуы рөхсәт ителә.

**152 статья.** Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды—идарә өлкәсендәге, предприятие, учреждение һәм оешмалар, шулай ук закон белән билгеләнгән тәртиптә эшмәкәрлек белән шөгыльләнүче гражданнар арасындагы икътисадый бәхәсләрне караучы югары суд органы.

Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының вәкаләте, оешу һәм эш тәртибе Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды турында Закон белән билгеләнә.

## 15 бүлек. ЗАКОНЛЫЛЫКНЫ ҺӘМ ХОКУК ТӘРТИБЕН САКЛАУ

**153 статья.** Татарстан Республикасындагы барлык министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволарның, предприятие, учреждение һәм оешмаларның, халык депутатлары җирле Советларының, җирле администрация һәм җирле үзидарәнең башка органнарының, колхоз, кооператив һәм җәмәгать берләшмәләренең, урындагы кешеләрнең, шулай ук гражданнарның законнарны төгәл һәм бертөрле үтәвен күзәтүне Татарстан Республикасы прокуроры һәм аңа буйсынган прокурорлар гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы прокурорының һәм аңа буйсынган прокурорларның эшчәнлеге Татарстан Республикасы законнарын катгый үтәүгә корыла, һәм ул законның өстенлеген тәэмин итүгә, законлылыкны ныгытуга юнәлтелә.

**154 статья.** Татарстан Республикасы прокуроры, Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме белән, Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан билгеләнә, ул аның алдында җаваплы һәм хисап бирә.

Татарстан Республикасы прокуроры урынбасарлары, район, шәһәр прокурорлары һәм башка прокурорлар Татарстан Республикасы прокуроры тарафынннан билгеләнә.

**155 статья.** Татарстан Республикасы прокурорының һәм түбәнге прокурорларының вәкаләт срогы—биш ел.

**156 статья.** Татарстан Республикасы Прокуратурасы органнары үз вәкаләтләрен кайсы да булса җирле органга бәйсез рәвештә гамәлгә ашыра һәм бары Татарстан Республикасы прокурорына буйсына.

Татарстан Республикасы Прокуратурасының вәкаләте, оешу һәм эш тәртибе Татарстан Республикасы Прокуратурасы турында Закон белән билгеләнә.

**157 статья.** Судка кадәр тикшерү үткәрү өчен Татарстан Республикасының Тикшерү комитеты оештырыла.

Тикшерү комитеты рәисе, Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме белән, Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан биш елга билгеләнә, ул Татарстан Республикасы Югары Советына буйсына һәм аның алдында җаваплы.

Татарстан Республикасы Тикшерү комитетының вәкаләте, оешу һәм эш тәртибе Татарстан Республикасы Тикшерү комитеты турында Закон белән билгеләнә.

Судка кадәр тикшерүне алып баруның законлылыгына күзәтчелекне Татарстан Республикасы прокуроры гамәлгә ашыра.

**158 статья.** Судларның, прокуратура һәм тикшерү органнарының хокук саклау эшчәнлегенә тыкшынырга беркемнең дә хакы юк. Бу органнарның хезмәткәрләре закон таләпләренә таянып эш итә һәм үзләренең хезмәт вазифаларын башкарганда җәмәгать берләшмәләре карарларына бәйле булмыйлар.

Татарстан Республикасы территориясендә җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча тикшерү һәм башка махсус эшләрне мөстәкыйль башкаручы хосусый, кооператив берләшмәләр һәм аларның бүлекчәләренең оешуы һәм эшчәнлеге тыела.

Татарстан Республикасында хосусый детектив һәм сак эшчәнлеге закон нигезендә рөхсәт ителә.

**159 статья.** Гражданнарга һәм оешмаларга юридик ярдәмне адвокатлар коллегияләре, ә законда каралган очракларда башка юридик оешмалар һәм аерым гражданнар күрсәтә.

Татарстан Республикасында адвокатураның оешу һәм эш тәртибе закон белән билгеләнә.

## VI. Татарстан Республикасының дәүләт символлары һәм башкаласы

**160 статья.** Татарстан Республикасының үзенең суверенитетын, Татарстан халкының үзенчәлеген һәм традицияләрен чагылдырган рәсми эмблемалары, символлары — Дәүләт гербы, Дәүләт флагы һәм Дәүләт гимны бар.

**161 статья.** Татарстан Республикасының Дәүләт гербы кояш җирлегендә алгы уң аягын бераз күтәргән, янтавында түгәрәк калканы булган канатлы барс сурәтеннән гыйбарәт. Кояш түгәрәге татар милли бизәге төшерелгән, аскы өлешенә «Татарстан» дип язылган кайма белән уратып алынган.

**162 статья.** Татарстан Республикасының Дәүләт флагы яшел, ак һәм кызыл төстәге аркылы буйлардан торган турыпочмаклы тукымадан гыйбарәт. Ак буй флаг киңлегенең 1/15 өлешен тәшкил итә һәм тигез киңлектәге яшел һәм кызыл төстәге буйлар уртасында урнашкан. Яшел буй — өстә.

Флагның киңлеге озынлыгына карата 1:2 нисбәтендә.

**163 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт гимнын Татарстан Республикасы Югары Советы раслый.

**164 статья.** Татарстан Республикасының башкаласы — Казан шәһәре.

## VII. Татарстан Республикасы Конституциясенең гамәлдә булуы һәм аны үзгәртү тәртибе

**165 статья.** Татарстан Республикасы Конституциясе — республиканың Төп Законы, ул турыдан-туры гамәли иң югары юридик көчкә ия акт. Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасының дәүләт органнары актлары Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә һәм аңа туры китереп чыгарыла.

**166 статья.** Татарстан Республикасының дәүләт органнары, җәмәгать берләшмәләре, урындагы кешеләре һәм гражданнары Татарстан Республикасы Конституциясен ихтирам итәргә һәм үтәргә бурычлы.

**167 статья.** Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасы Югары Советының билгеләнгән санлы составының кимендә әчтән икесеннән күбрәгенең тавышы белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Югары Советы карары нигезендә үзгәртелә.

**Татарстан Республикасы Президенты**
**М. Ш. ШӘЙМИЕВ.**

## ТЕЛЕВИДЕНИЕ

**ЯКШӘМБЕ**
**20 ДЕКАБРЬ**

**ТАТАРСТАН КАНАЛЫ**

7.00—8.00 Чулпан. Информацион-музыкаль программа.
17.10 Балалар өчен. «Бергәләп өйрәник» тапшыруына кушымта.
17.40 Кинореклама.
17.45 «Кияү белән кәләш». Спектакль.
19.25 Әлли-бәлли-бәү.
19.45 Ял концерты.

**ОСТАНКИНО КАНАЛЫ**

7.00 «Рухи көч сәгате».
8.00 «Спортлото» тиражы.
8.15 Мультфильм.
8.30 «Алтын чәчелмәләр».
9.00 Док. фильм.
9.30 Иртән-иртүк.
10.00 Бар да өйдә чакта.
10.30 Иртәнге йолдыз.
11.20 Дөньяның буш вакыты.
12.00 «Кара Чибәр маҗаралары». 23 серия.
12.25 Яшь буын сайлый.
13.15 Халык көйләре.
13.30 «Пиф һәм Геркулес».
13.40 Кусто командасының су асты одиссеясы.
14.30 Музаларга хезмәт ыгы-зыгыны яратмый.
15.00 Яңалыклар.
15.20 «Туры эфирда диалог».
16.00 «Сәяхәтчеләр клубы».
16.50 Һөнәрләрнең тере агачы.
17.00 «Панорама».
17.40 «Телелоция».
17.55 «Уолт Дисней тәкъдим итә...»
19.00 «Оба-на-Угол» шоу.
19.50 «Анфиса» фильм-спектакль.
22.00 «Нәтиҗәләр».
22.45 Спорт уикэнде.
23.00 Матадор.
00.00 Яңалыклар.
00.25 Кул сугышы чемпионаты.
01.00 «Сыңарлар балы».

**«РОССИЯ» КАНАЛЫ**

8.00 Хәбәрләр.
8.20 Мульти-пульти.
8.30 Документаль панорама.
9.20 1812 елгы давыл.
9.50 Безнең бакча.
10.20 «Корольлектәге маҗара». 17 серия.
10.30 «Аты баты».
11.20 Рек-тайм.
11.50 «Шәһрезаданең яңа әкиятләре». 2 серия.
12.55 «Смирновлар гаиләсе».
13.40 «Крестьян мәсьәләсе».
14.00 «Хәбәрләр».
14.20 Юнып ташлап булмый.
14.35 Параллель дөньялар.
15.20 «Дораэмон». 15 серия.
15.35 Познер һәм Донахью.
16.05 Репортер.
16.20 Ак карга.
17.05 Кинокомедия.
19.10 «Сары су асты көймәсе» клубы.
19.45 Көн дә бәйрәм.
20.00 Хәбәрләр.
20.20 «Афәрин, сатира».
21.50 СИ-БИ-ЭС Россия телевидениесендә.
22.00 Хакыйкать мизгеле.
23.00 Хәбәрләр.
23.30 ЭС-ЭН-СИ төнге клубы.

## *20 декабрь—Энергетиклар көне*

☆ ☆ ☆



Лидия Аркадьевна Агеева — шәһәр электр челтәрендә Светлана Владимировна Кузнецова белән бергә контролер булып эшли. Алар быел гына да өч дистәгә якын электр энергиясен урлаучыларның кырын эшен ачканнар. Контролерлар тырышлыгы белән 30 мең сумнан артык дәүләт средствосы кайтарылган.

Әлеге хатыннарга контроль эше генә йөкләнмәгән, билгеле. Аларның куллары электр счетчикларын да «дәвалый». Бу безнең заманда мөһим эш. Чөнки яңа счетчикка 3 мең сум түләргә кирәк, ә ремонт өчен барлыгы 32 сум гына түләнә.

Шәһәр электр челтәре коллективы үзләренең профессиональ бәйрәмнәрен һәр елны 20 декабрьдә билгеләп үтәләр. Алар аны, кагыйдә буларак, гаилә белән бергә бәйрәм итәләр. Менә быел да элеккеге гадәт буенча бәйрәм кичәсе үткәрергә булдылар. Бәйрәмнәрне болай билгеләп үтү коллективның дуслыгы, татулыгы турында сөйли һәм бу традиция озак еллар буена шулай дәвам итәр, дип ышанасы килә.

Энергетикларны бәйрәмнәре белән котлыйбыз.

РӘСЕМДӘ: Лидия Аркадьевна Агеева.

### ИШЕТМӘСӘҢ — ИШЕТ!

**БАКЫР**

Яра төзәлүгә, кан тамырлары киңәйгәндә булышлык итә. (Көнбатышта бу максатта каптырмалы махсус бакыр пластинкалар кулланалар). Бездә андый мөмкинлек булмагач, 1961 елга чаклы чыгарылган бакыр акчалардан файдаланырга мөмкин. Кызыл бакыр биш тиенлекләрне радикулит булганда оча башы сөягенә беркетәләр яки билгә салалар һәм эт тиресе ябалар. Бакыр чыбыкны үзеңә урарга мөмкин.

Кеше авыру икән, бакыр аңа кагылганда карала. Бу очракта аны тозлы суда юарга һәм чистартырга кирәк.

Күптән түгел генә барысы да мавыккан бакыр браслетлар терсәктән әйләндереп алынган булса гына кан басымын яхшырта.

✦

**2. Күп илләр медицинасына ябык авыруларга бирелә торган средстволар билгеле. Шуларның берсен тәкъдим итәбез.**

**400 грамм дуңгызның эч маен һәм алты яшел алма алып турарга, болгатырга һәм эретергә. Аннары 12 йомырка сарысын алып бер стакан шикәр комы белән болгатырга. Шуңа ук 400 грамм вакланган шоколад өстәргә. Алмалы майны иләктән үткәреп теге катнашмага кушарга. Суытырга. Алынган продуктны көненә 3—4 мәртәбә икмәккә ягып ашарга. Артыннан кайнар сөт эчәргә.**

### ТАТАРЛАРГА КИТАПХАНӘ КИРӘК

1904 елның көзендә үк шәһәр Думасы Казанның Болак арты өлешендә мөселманнар өчен җәмәгать китапханәсе бүлеге ачу турында карар кабул иткән һәм шушы максатка 590 сум акча бүлеп биргән иде.

Татарлар моңа шатландылар, әмма идарә бу карарны шушы көнгә кадәр үтәми...

Татарлар зур мохтаҗлык кичерәләр, бу бердәнбер татар китапханәсе булыр иде.

**«Волжский листок», 1905 ел, 10 июнь.**





**Норлат шәһәрендә яшәүче Галиулла Галиәскәр улы Вәлиәхмәтовны 60 яше белән котлыйбыз.**

**Ходай сиңа сәламәтлек бирсен,**
**Син булганга өебез нур чәчә.**
**Киңәшчебез, терәгебез булып**
**Яшә, эти, матур, йөзгәчә.**

**ТОРМЫШ ИПТӘШЕ, КЫЗЛАРЫ, КИЯҮЛӘРЕ, УЛЫ, КИЛЕНЕ, ОНЫКЛАРЫ.**

**БЕЛДЕРҮЛӘР**

«Арсиан» кече предприятиесе, Татарстанга, Башкортстанга, Россиягә күчеп кайтучыларга бушлай ярдәм итә.

Шулай ук йорт-җир сатып ала.

Безнең адрес: 195426, Петербург шәһәре, абонемент ящик №3. «Арсиан» Кече Дәүләт предприятиесенең маркетинг буенча директоры Ринат Вәлиевка.

⊙ ⊙ ⊙

**Октябрь райпосы коопзаготпромы халыктан 1 килограммын 2 сум 65 тиенгә макулатура кабул итә.**



**Мөхәррир урынбасары Р. З. АИЗАТУЛЛИН**

**Учредительләр: редакциянең хезмәт коллективы һәм халык депутатларының Октябрь районы Советы.**

**Редакциянең адресы: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19. Телефоннар: мөхәррир 2—12—14, 2—22—81; мөхәррир урынбасары һәм Советлар тормышы бүлеге 2—10—44, рус теленә тәрҗемә итү буенча мөхәррир урынбасары 2—14—16, чуваш теленә тәрҗемә итү буенча мөхәррир урынбасары 2—15—63; авыл хуҗалыгы бүлеге 2—10—44; яңалыклар һәм промышленность бүлеге 2—22—51, җаваплы секретарь, хатлар, массалар белән эшләү, радиотапшырулар бүлеге, бухгалтерия һәм реклама бүлеге 2—18—67; фотокорреспондент 2—15—63.**

**Газетаның басылу сыйфаты турында типография директорына түбәндәге телефон белән мөрәҗәгать итәргә: 2-10-54.**

**Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Фирдания ХУҖИӘХМӘТОВА басты. Корректор—Зөлфия ВӘЛИЕВА. Күләме—1 басма табак.**

**Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә. Татарстан Республикасы информация һәм матбугат Министрлыгының Норлат-Октябрь типографиясе.**

**Тираж 3751. Заказ 151.**